ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШЛЫГЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail:balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

18.11.2021 Балык Бистәсе штп. № 233пг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында яңа редакциядәге нигезләмә;

Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе составы.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2019 елның 13 февралендәге 41 пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр

кертү хакында"  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 29 октябрендәге  89 пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2019 елның 25  гыйнварындагы   26 пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2020 елның  24 августындагы  142 пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2020 елның  5 октябрендәге  162 пг номерлы карарын;

"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында" 144пг номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының 2021 елның  24 февралендәге  70 пг номерлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне  үземнең җаваплылыкта калдырам.

И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2021 елның 18 ноябрендәге
233 пг номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру максатларында оештырылган даими эшләүче яраштыру органы булып тора.

1.2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, башка муниципаль норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашыра.

## II. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

а) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе карарларын үтәүне тәэмин итү;

б) Балык Бистәсе муниципаль районында Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе утырышларында кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итү;

в) Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү;

г) коррупциягә каршы тору өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) эшчәнлеген яраштыруны (килештерүне) тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашырганда җирле үзидарә органнарының федераль дәүләт органнарының территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының территориаль органнары белән хезмәттәшлеген (багланышын) тәэмин итү;

е) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарының гражданнар, граждан җәмгыяте институтлары, гаммәви мәгълүмат чаралары, фәнни оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

ж) җәмәгатьчелеккә коррупциягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан алып барыла торган эш турында мәгълүмат бирү.

## III. Комиссиянең вәкаләтләре

3.1. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгына коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары кысаларында кабул ителгән муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

б) коррупциягә каршы тору, шулай ук коррупцияне (ришвәтчелекне) китереп чыгара торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар эшли;

в) коррупциягә каршы түзеп тормаучан мөнәсәбәт һәм ришвәтчелеккә каршы үз-үзеңне тоту стандартларын формалаштыру максатларында коррупциягә каршы гражданнарны агартуны (белемле итүне) оештыру буенча тәкъдимнәр эшли;

г) коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларын әзерләүне оештыра;

д) коррупциягә каршы муниципаль программа эшләүне, шулай ук аны тормышка ашыруны, шул исәптән әлеге программада каралган коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау юлы белән дә, контрольдә тотуны оештыра;

е) административ киртәләр тудыра торган коррупцияне барлыкка китерүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау (шул исәптән гражданнар мөрәҗәгатьләре, гаммәви мәгълүмат чаралары тарафыннан таратыла торган белешмәләр, протестлар, тәкъдимнәр, федераль дәүләт органнары күрсәтмәләре нигезендә), бетерү һәм минимальләштерү чараларын күрә;

ж) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы муниципаль программасын тормышка ашыруга җәмәгатьчелек контролен үстерүгә булышлык итә;

и) коррупциягә каршы тору өлкәсендә эшчәнлек турындагы еллык доклад (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының коррупция торышы һәм ришвәтчелеккә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында җыелма хисабын) әзерләүне тәэмин итә, аны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны, гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнарына (аларның гарызнамәләре буенча) җибәрүне тәэмин итә;

к) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары бүлекчәләреннән (вәкилләреннән), җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан (милек рәвешләренә бәйсез рәвештә) һәм вазыйфаи затлардан кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә сората һәм алдыра;

л) җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашырганда Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары бүлекчәләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, граждан җәмгыяте институтлары һәм гаммәви мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен кирәкле башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Комиссияне формалаштыру (төзү) тәртибе

4.1. Комиссия турында Нигезләмә һәм аның персональ составы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

4.2. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасарлары, сәркатибе һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

4.3. Комиссия рәисе булып Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы яки аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат тора.

4.4. Комиссия составына Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкилләре, Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый советы вәкилләре, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләре, шул исәптән фәнни һәм белем бирү оешмалары, коррупциягә каршы торуда катнашу устав бурычларында булган иҗтимагый оешмалар вәкилләре керергә мөмкин.

4.5. Комиссия әгъзасы вәкаләтләрен башка затка тапшыру рөхсәт ителми.

4.6. Комиссия эшендә катнашу җәмәгатьчелек башлангычында гамәлгә ашырыла.

4.7. Комиссия утырышларына федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.8. Комиссия рәисе карары нигезендә Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча эксперт бәяләмәсен анализлау, өйрәнү һәм әзерләү өчен вакытлы яки даими нигездә экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

## V. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эшләү тәртибе

5.1. Комиссия эше план нигезендә һәм Комиссия раслый торган регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Комиссия утырышларын Комиссия рәисе яисә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

5.3. Комиссия утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Зарурлык булганда Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, шулай ук Комиссия әгъзасы инициативасы буенча, Комиссия рәисе белән килештереп һәм Комиссия сәркатибе тәкъдиме буенча Комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.4. Комиссия утырышлары ачык рәвештә үткәрелә (Комиссия әгъзасы булмаган затларның булуы рөхсәт ителә). Тиешле мәсьәләләрне караганда Комиссия рәисе яисә ул булмаганда комиссия рәисе урынбасары тарафыннан конфиденциальлекне тәэмин итү максатларында Комиссиянең ябык утырышын уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин (Комиссия әгъзалары һәм утырышка чакырылган затлар гына катнаша).

5.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5.6. Комиссия утырышы әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлешенең анда катнашу очрагында тулы хокуклы (вәкаләтле) булып санала.

5.7. Комиссия карарлары утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Утырыш беркетмәсенә комиссия сәркатибе имза сала һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

5.8. Комиссия рәисе карары буенча Комиссия карары Комиссия әгъзаларын язма рәвештә сораштыру (читтән торып тавыш бирү) үткәрү юлы белән кабул ителергә мөмкин.

5.9. Комиссия карарларын тормышка ашыру өчен Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының муниципаль хокукый актлары чыгарылырга, шулай ук Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының йөкләмәләре (йомышлары) бирелергә мөмкин.

5.10. Комиссия карары буенча Комиссия әгъзалары яисә алар тарафыннан вәкаләтләр бирелгән вәкилләр, шулай ук җирле үзидарә органнары вәкилләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм экспертлар арасыннан аерым мәсьәләләр буенча эшче (эксперт) төркемнәре төзелергә мөмкин.

5.11. Комиссия рәисе:

а) Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

б) Комиссиянең эш планын раслый ( һәр елга еллык план);

в) комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

г) үз вәкаләтләре кысаларында комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә (йомыш куша);

д) федераль дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Комиссияне тәкъдим итә.

5.12. Комиссия сәркатибе:

а) Комиссия эшен оештыра;

б) Комиссиянең эш планы проектын (еллык план) әзерләүне тәэмин итә, аның утырышының көн тәртибен формалаштыра, Комиссия утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен яраштыра (килештерә);

в) Комиссия утырышын уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында Комиссия әгъзаларына, утырышка чакырылган затларга, экспертларга, башка затларга хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

г) Комиссиядә эш башкаруны (делопроизводствоны) оештыра һәм алып бара;

д) Комиссия карарлары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

е) Комиссия рәисенең Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча бирелгән йөкләмәләренең (йомышларының) үтәлешен оештыра;

ж) Комиссиянең Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы Идарәсе белән хезмәттәшлеген (багланышын, элемтәсен) тәэмин итә.

5.13. Комиссия әгъзалары:

а) Комиссия, Комиссия рәисе карарлары һәм Комиссия әгъзалары тәкъдиме нигезендә карауга кертелә торган мәсьәләләрне әзерләүне оештыралар;

б) үзләренең вазыйфаи вәкаләтләре кысаларында Комиссия карарларын үтәүне оештыралар;

в) Комиссия эшчәнлеген регламентлаштыра торган хокукый актлар таләпләрен үтиләр;

г) үзләре вәкил булып торган органның компетенция чикләрендә күрсәтелгән органның Комиссия һәм аның сәркатибе белән багланышын оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны тәгаенлиләр.

5.14. Комиссия әгъзалары хокуклы:

а) утырышларда чыгыш ясарга;

б) Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә;

в) Комиссия утырышларында тавыш бирергә;

г) Комиссия эшчәнлегенә турыдан-туры кагылышлы материаллар белән танышырга;

д) Комиссия рәисе белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалары хезмәткәрләрен һәм белгечләрен Комиссия эшчәнлегенә бәйле экспертлык, аналитик һәм башка эшкә җәлеп итәргә.

5.15. Комиссия рәисе карары буенча Комиссия карарлары турында мәгълүмат гаммәви мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшырыла ала, шулай ук “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

5.16. Комиссия үз исеме белән аерым бланкка ия.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2021 елның 18 ноябрендәге
233 пг номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында
Коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Тажетдинов И.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы, Комиссия рәисе |
| Исланов Р.Л. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Комиссия рәисе урынбасары |
| Әсләмов Х.Г. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, Комиссия сәркатибе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Ананьева Л.Р. | “Татмедиа”АҖ филиалы директоры – «Сельские горизонты» (“Авыл офыклары”) газетасының баш мөхәррире (килешенү буенча) |
| Бәдретдинов А.И. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисе |
| Вафина А.К. | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килешенү буенча) |
| Вафин Ф.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Гаязов Д.Р. | “Балык Бистәсе РҮХ “ ДАССУ нең баш табибы (килешенү буенча) |
| Җамалиев Р.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Иминова Р.Г. | Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килешенү буенча). |
| Керженцева Г.Ф. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУ директоры (килешенү буенча) |
| Малакаева В.И. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы һөнәр берлекләренең координацион советы рәисе (килешенү буенча) |
| Мингалиев М.З. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Мөгыйнов Р.А. | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Биектау районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Мостафин Н.Ф. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Ногманова И.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Писковцев С. | протоиерей, Балык Бистәсе муниципаль районы храмнары благочинные (килешенү буенча) |
| Рәшитова Р.Г. | “Ак калфак” иҗтимагый берләшмә рәисе, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Социаль-мәдәни өлкә бүлеге” МКУ башлыгы (килешенү буенча) |
| Романов А.А. | “Керәшен” Җәмгыяте рәисе (килешенү буенча) |
| Садиков И.М. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге” МКУ башлыгы (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Токранов В.И. | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары (килешенү буенча) |
| Хисаметдинов Р.Р. | Балык Бистәсе муниципаль районы мөхтәсибе (килешенү буенча) |
| Шәвәлиев Р.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе (килешенү буенча) |
| Шакиров И.З. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ башлыгы (килешенү буенча) |